МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

03.06.2019　　　　　г.Казань　　　　　№ _543-осн_

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертип нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның 6 июлендәге 513-осн номерлы боерыгы (2018 елның 4 апрелендәге 186-осн номерлы боерык нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җәмгыятьтә коррупциячел торышка сабырсызлык формалаштыру».

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый советта каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциясез оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.»

Министр　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Ә. Кузюров